КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 4 июль г.Казань № 637

Медицина реабилитациясен гамәлгә ашыручы медицина оешмаларын медицина әйберләре белән җиһазландырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сәламәтлек саклауны үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 26 декабрендәге 1640 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Медицина реабилитациясен гамәлгә ашыручы медицина оешмаларын медицина әйберләре белән җиһазландырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 4 июль, 637 нче
карары белән расланды

Медицина реабилитациясен гамәлгә ашыручы медицина оешмаларын медицина әйберләре белән җиһазландырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү тәртибе

1. Бу Тәртип медицина реабилитациясен гамәлгә ашыручы медицина оешмаларын (алга таба – медицина оешмалары) медицина әйберләре белән җиһазландырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү механизмын билгели.

2. Медицина оешмаларын медицина әйберләре белән җиһазландырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 461 нче карары белән расланган «2025 елга кадәр Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау системасын үстерү» дәүләт программасына кертелгән һәм «Сәламәтлекне торгызу өчен оптималь медицина реабилитациясе» федераль проекты максатларына, күрсәткечләренә һәм нәтиҗәләренә ирешүне тәэмин итә торган үз структурасында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомство буйсынуындагы олыларның һәм балаларның медицина реабилитациясен оештыру тәртипләре нигезендә медицина реабилитациясе буенча медицина ярдәме күрсәтү бүлекчәләре булган медицина оешмаларын медицина әйберләре белән җиһазландыру (җиһазландырып бетерү һәм (яки) яңадан җиһазландыру) чараларын тормышка ашырганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бирелә торган субсидия (алга таба – субсидия) һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

Медицина әйберләренең технологик тасвирнамәләре эквивалент булганда Россия җитештерүчеләренең медицина эшләнмәләренә өстенлек бирү тәкъдим ителүен исәпкә алып, медицина оешмаларын медицина әйберләре белән җиһазландыру олыларның һәм балаларның медицина реабилитациясен оештыру тәртибендә каралган җиһазландыру стандартлары (алга таба – җиһазландыру стандартлары) нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Бу Кагыйдәләрнең 2 пунктында күрсәтелгән чараларны тормышка ашыруга каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тора.

4. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы медицина эшләнмәләре белән җиһазландыру өчен акчаны Яр Чаллы шәһәренең «7 нче шәһәр хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә, «Кама балалар медицина үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә, «Медицина реабилитациясе буенча балалар үзәге» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенә җиһазлау стандартлары нигезендә җибәрә.

5. Акчаны тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгында ачылган шәхси счет аша башкарыла.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан финанслауның иң чик күләмнәрен җиткергәннән соң расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә җиткерә.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы:

дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә бу Тәртипнең 2 пункты нигезендә медицина эшләнмәләрен сатып алуга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзи;

медицина эшләнмәләрен сатып алуга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзелгән оешмаларга акча күчерә.

8. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы финанслашу максатларында субсидия бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында, шулай ук субсидиядән файдалану нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә ителә торган дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында субсидия бирү турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә, формада һәм срокларда хисаплылык урнаштыра.

9. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә акчаны максатчан файдаланмаган өчен җавап бирә.

10. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына акчаның файдаланылмый калган өлеше Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

___